| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

Иске Шөгер

26 марта 2021ел № 20

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Шөгер авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә «Иске Шөгер авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Иске Шөгер авыл жирлеге «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Иске Шөгер авыл жирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында" Татарстан Республикасы Законына үзгерешләр кертү турында" 2020 елның 26 декабрендәге Татарстан Республикасы Законы, Ттатарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Иске Шөгер авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Шөгер авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә «Иске Шөгер авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Иске Шөгер авыл жирлеге «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Иске Шөгер авыл жирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 статьяның 4.15 пунктында "хезмәт кенәгәсе" сүләреннән соң "(булганда)" сүзләре белән тулыландырырга;

6 статьяны түбәндәге эчтәлекле 6.6 пункт белән тулыландыырырга:

«6.6 Жирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты житәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге жирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар.»;

10 статьяда 10.1.3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

20.1 статьяда 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәжбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;».

2. Әлеге карарны Иске Шөгер авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә; әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында(leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә и татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

"Иске Шөгер авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы
Совет рәисе Л.М.Шиһапова